ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18. 04. 2024 Балык Бистәсе штп. № 93пи

Хөкем ителгәннәргә төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү урынын, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәгәндә эшләр төрләрен билгеләү турында

«Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте Идарәсенең Татарстан Республикасы буенча җинаять-башкарма инспекциясе» Федераль казна учреждениесенең Лаеш муниципальара филиалы мөрәҗәгатен карап, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 статьясындагы 1 өлеше, 50 статьясындагы 1 өлеше, Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 25 статьясындагы 1 өлеше, 39 статьясының 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә яшәүче төзәтү һәм мәҗбүри эшләргә хөкем ителүчеләрнең җәзаларын үтәтү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Расларга:

Хөкем ителгәннәрне эш урыннары булган очракта төзәтү эшләренә җибәрү, аларны эшкә урнаштыру һәм хөкем карары (билгеләмә, карар) буенча җәза үтәү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр исемлеген;

мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәрнең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында башкарачак эш төрләрен.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Хөкем ителгәннәргә төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү урынын, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәгәндә эшләр төрләрен билгеләү турында” 2022 елның 19 сентябрендәге 238 пи номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. «Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте Идарәсенең Татарстан Республикасы буенча җинаять-башкарма инспекциясе» Федераль казна учреждениесенең Лаеш муниципальара филиалына әлеге карарның бер нөсхәсен җибәрергә.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балык Бистәсе муниипаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә

Җитәкче Д.А. Сатдинов

муниципаль районы Башкарма
комитетының 2024 елның 18
апрелендәге 93 пи номерлы карары
белән расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы территориясендә яшәүче төзәтү эшләренә хөкем ителгән затларга, җәза бирүне үтәтү өчен оешмалар, предприятиеләр һәм учреждениеләр

ИСЕМЛЕГЕ

(алдан килешү буенча төзелде)

| № | Исеме | ИНН | Адрес |
|---|---|---|---|
| 1. | "Теплоэнергосервис»МУП | 1634009125 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., Ленин ур., зд.48А |
| 2. | "Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы" ДБУ; | 1634008675 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы, Парк ур., 9 |
| 3. | "Кызыл Йолдыз урманчылыгы" ДКУ | 1634005931 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы, Парк ур., |
| 4. | «Татавтодор» АЖ («Татавтодор» АЖ шәһәр яны филиалының «Балык Бистәсе»ДРСУ) | 1660110241 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., З.Шәймарданов ур., 69 йорт. |
| 5. | "Масловский " ААЖ | 1634003860 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Масловка авылы, Үзәк ур., 15 йорт. |
| 6. | «Логос»ЖЧЖ | 1634002169 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., Октябрь ур. |
| 7. | «Кама-Агро»ЖЧЖ | 1634009220 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Олы Елга авылы,Октябрь ур., 26 йорт. |
| 8. | «Солтан «Агрофирмасы»ЖЧЖ | 1634006251 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Олы Солтан авылы, Кече ур., 1йорт. |
| 9. | «Зюзино «Агрофирмасы»ЖЧЖ | 1634006580 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., Причал ур., 8йорт |
| 10. | «Кулон Агро»ЖЧЖ | 1634008530 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Яңа авыл авылы. |
| 11. | «Урахча»ЖЧЖ | 1634005392 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Урахча авылы. |
| 12. | «Балык Бистәсе Агрохимсервис»ЖЧЖ | 1634004423 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., Причал ур. |
| 13. | «Балык Бистәсе ХПП»ЖЧЖ | 1655401728 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., Восточная ур., 12йорт |
| 14. | «Арыш»ЖЧЖ | 1634004776 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Хутор авылы,Хутор ур., 1 йорт. |
| 15. | «Круг»ЖЧЖ | 1634001912 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., Яр буе ур., 9 йорт |
| 16. | «Бистә-2»СПСК | 1634006357 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп.,Тынычлык ур., 17йорт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 17. | «Кама» КЖ | 1634008731 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., Бакча тык., 7йорт |
| 18. | «Дуслык» КЖ | 1634008717 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., Бакча тык., 7йорт |
| 19. | "Кама Плюс" КЖ | 1634004920 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Балык бистәсе штп., З.Шәймарданов ур., 71йорт |
| 20. | «Балык Бистәсе»ВЗП | 1634006170 | ТР, Балык Бистәсе р - ны, Югары Тегермәнлек авылы,Совет ур., 8а йорт. |

муниципаль районы Башкарма
комитетының 2024 елның 18
апрелендәге 93 пи номерлы карары
белән расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында мәҗбүри эшләргә хөкем ителгәннәр башкарачак

ЭШ ТӨРЛӘРЕ

(алдан килешү буенча төзелде)

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең һәм Балык Бистәсе штп.ның тышкы төзекләндерү объектларын яшелләндерү, агымдагы карап тоту һәм үстерү буенча эшләр.

2.Урам территорияләрен җыештыру.

Анатыш авыл җирлеге башкарма комитеты
Балыклы Чүкәй авыл җирлеге башкарма комитеты
Бәтке авыл җирлеге башкарма комитеты
Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты
Олы Елга авыл җирлеге башкарма комитеты
Олы Кульга авыл җирлеге башкарма комитеты
Зур Мәшләк авыл җирлеге башкарма комитеты
Олы Әшнәк авыл җирлеге башкарма комитеты
Олы Солтан авыл җирлеге башкарма комитеты
Казак Чаллысы авыл җирлеге башкарма комитеты
Корноухово авыл җирлеге башкарма комитеты
Күгәрчен авыл җирлеге башкарма комитеты
Күки авыл җирлеге башкарма комитеты
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башкарма комитеты
Масловка авыл җирлеге башкарма комитеты
Түбән Тегерменлек авыл җирлеге башкарма комитеты
Яңа Арыш авыл җирлеге башкарма комитеты
Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты
Рус Әшнәге авыл җирлеге башкарма комитеты
Трой Урай авыл җирлеге башкарма комитеты
Уракчы авыл җирлеге башкарма комитеты
Шомырбаш авыл җирлеге башкарма комитеты
Югары Ырга авыл җирлеге башкарма комитеты
Шомбыт авыл җирлеге башкарма комитеты
Шумково авыл җирлеге башкарма комитеты
Юлсубино авыл җирлеге башкарма комитеты
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитеты